СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«УРМЫШЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ОРМЫШЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

2024 елның 1 августы

№ 20

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның, 26 октябрендәге 35 номерлы (15.10.2018 № 27, от 29.11.2018 № 33, от 01.03.2023 № 2, от 10.04.2023 № 13 үзгәрешләр белән) карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның, 26 октябрендәге 35 номерлы ( 15.10.2018 № 27, от 29.11.2018 № 33, от 01.03.2023 № 2, от 10.04.2023 № 13 үзгәрешләр белән) карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) карарның 2 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац белән тулыландырырга:

«Гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы күрсәтмәсе белән раслана торган исемлеккә кертелгән урыннарга карата 1,2 процент;»;

2) карарның 2 пунктындагы 4 пунктчасының дүртенче һәм бишенче абзацларын тиешенчә бишенче һәм алтынчы абзацлар дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Урмышлы ав., Үзәк ур., 4 й.; Яңа Елховой ав., Чишмә ур., 22 й.; Бохар авылы, Авангард ур., 23 й.; адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә һәм 2025-2027 еллар салым чорларына гамәлдә була.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Урмышлы авыл җирлеге
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе

А.Ф.Хәбибуллин